Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле поселогы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Круглое Поле поселогы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр очен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар очен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Круглое Поле поселогында «Железнодорожник» паркы территориясен төзекләндерү (канализация челтәрен ремонтлау, фонтан элементларын буяу һәм урнаштыру, эскәмияләр очен төзелеш материаллары сатып алу һәм урнаштыру);
- Круглое Поле поселогында Вокзал урамы буенча тукталыш павильоны сатып алып урнаштыру;
- Круглое Поле поселогы Гагарин урамы буенча күпфатирлы йортлар яны территорияләрен төзекләндерү (вак таш җәю, асфальт валчыгы сатып алу, ташу, җәю).
- Круглое Поле поселогында урам яктырткычларын сатып алып урнаштыру;
- Круглое Поле поселогында материаллар сатып алып канализация челтәрләрен ремонтлау;
- Круглое Поле поселогы территориясен төзекләндерү (җил аударган агачларны кисү);
- Круглое Поле поселогында юлларны, тротуарны ремонтлау;
- Круглое Поле поселогында мәйдан территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм эстраданы, эскәмияләрне ремонтлау, буяу, агачларны кисү, үлән чабу);
- Круглое Поле поселогында зиратны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, буяу һәм күчерү, инвентарь саклау өчен хуҗалык блогын ремонтлау);
- Круглое Поле поселогында янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзекләндерү (төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу, махсус техника хезмәте).?"

2. Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Круглое Поле авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Низамиева